**Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы**
**Бакырчы авыл җирлегенең Үтәмеш торак пунктында**
**ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

**22 ноябрь 2019 ел** **№ 2**

2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 маддәләре, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 маддәсе нигезендә, Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районының Бакырчы авыл җирлегенең Үтәмеш торак пунктында гражданнар җыены **КАРАР ИТТЕ:**

1. Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районыны Бакырчы авыл җирлегенең Үтәмеш торак пунктында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, көндезге бүлектә укучы студентлар, күпбалалы гаиләләр, балачактан инвалидлар, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның һәм аларның тол хатыннары, Россия Федерациясе Кораллы Көчләре сафларына хезмәткә чакырылган гражданнар, иректән мәхрүм итү урыннарындагы гражданнардан тыш, 2020 елда 1000 сум күләмендә үзара салым кертүне гамәлгә ашырырга.

2. Аннан алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен, түбәндәге эшләрне башкару өчен юнәлдерергә:

- Үтәмеш авылы эчендәге Ленин ур., К.Маркс ур. юлларны төзү һәм төзекләндерү;
- Үтәмеш авылы зираты территориясен коймa белән әйләндереп алу;
- Үтәмеш авылындагы обелиск тирәсенә брусчатка сатып алу һәм аны җәю.

**Халык җыенында**
**рәислек итүче** **Л.С. Семенова**

**Татарстан Республикасы**
**Тәтеш муниципаль районы**
**Бакырчы авыл җирлеге башлыгы**
**урынбасары** **С.Г. Батталов**